ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
09.04.2019

КАРАР
№ 45

с. Введенская Слобода

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге торак пунктларының территорияләрен төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту буенча икеайлык үткәрү турында**

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге торак пунктларының территорияләрен төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен оештыру һәм халыкның экологик иминлегенә җавап бирерлек итеп тәртипкә китерү өчен

1. Введенский Бистәсе авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту икеайлыгын 2019 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр игълан итәргә.
2. 2019 елга Введенский Бистәсе авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составын расларга (1нче кушымта).
3. 2019 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү буенча чаралар планын расларга (2 нче кушымта).
4. Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләренә, милек формасына карамастан, тирә-юньдәге территорияләрне санитар чистарту эшен оештырырга, икеайлык кысаларында оештырылган полигонга һәм чүплеккә каты көнкүреш калдыклары чыгару өчен йөк транспорты бүлеп бирергә тәкъдим итәргә. Урыннарда агачлар һәм куаклар утырту, биналарның фасадларын, балалар мәйданчыкларын ремонтлау эшен оештырырга.
5. Нинди хокукка карамастан, авыл җирлеге территориясендә күчемсез милек булган гражданнарга йорт яны территорияләрен санитар чистарту буенча эш үткәрергә тәкъдим итәргә.
6. Введенский Бистәсе авыл җирлеге мәгълүмат стендларында әлеге карарны игълан итәргә.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Введенский Бистәсе
авыл җирлеге Башлыгы                                        Д.В. Морозов

Введенский Бистәсе авыл җирлеге
Башкарма комитетының
№ 45, 2019 елның 9 апреле
карарына
1 нче кушымта

Введенский Бистәсе авыл җирлеген төзекләндерү буенча
комитет составы

1. Морозов Дмитрий Владимирович – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башлыгы
2. Алексеев Александр Николаевич - 3нче номерлы Введенский Бистәсе бермандатлы сайлау округы буенча депутат
3. Алсуфьева Елена Юрьевна – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре
4. Игнатьева Савия Вагизовна – 5 нче номерлы Савин бер мандатлы сайлау округы буенча депутат

Введенский Бистәсе
авыл җирлеге Башлыгы Д.В. Морозов

Введенский Бистәсе авыл җирлеге
Башкарма комитетының
№ 45, 2019 елның 9 апреле
карарына
1 нче кушымта

Икеайлык кысаларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә санитар-экологик хәлне яхшыртуга юнәлдерелгән төзекләндерү һәм санитар чистарту буенча чаралар планы

| № | Чараның исеме | Үткәрү вакыты | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан чүплекләрне бетерү буенча эшләрне оештыру һәм үткәрү | Апрель | Введенский Бистәсе авыл җирлеге депутатлар корпусы |
| 2. | Торак пунктлар территорияләрен чүп-чардан җыештыру | Апрель | Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты депутатлар корпусы |
| 3. | Шәхси торак йортларның йорт яны территориясен җыештыру | Апрель | Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты халык |
| 4. | Авыл җирлеге территориясендә торак пунктлар эчендә баганалар агарту | Май | Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты Введенский Бистәсе МБОУ «Төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБДОУ «Введенский Бистәсе балалар бакчасы» |
| 5. | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан учреждение, предприятие биналарының фасадларын ремонтлау | Май | Оешма, предприятие җитәкчеләре |
| 6. | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны төзекләндерү (коймаларны ремонтлау, коймаларны буяу, чүп чыгару) | Май | Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты халык |
| 7. | Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасы территориясен төзекләндерү | Май | Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 8. | Введенский Бистәсе авыл җирлеге торак пунктларында яшел үсентеләр утырту | Май | Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты, Введенский Бистәсе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | МБОУ «Төп гомуми белем бирү мәктәбе» |
| 10. | Сәүдә мәйданчыкларында һәм җәмәгать туклануы объектларында санитар-гигиена таләпләрен төзекләндерү һәм үтәү буенча эшләр алып барырга | даими | Сәүдә нокталары һәм җәмәгать туклануы пунктлары хуҗалары |

Введенский Бистәсе
авыл җирлеге Башлыгы Д.В. Морозов